Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Югары Лашчы авыл җирлеге составына керүче Чуаш Аксуы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре

01 март 2022 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131 номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 01 мартында узган «2021 елның 09 декабрендәге 1 номерлы Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Югары Лашчы авыл җирлегенең Чуаш Аксуы авылы гражданнары җыены карары нигезендә җыелган гражданнарның үзара салым акчаларын Чуаш Аксуы авылында юлларны төзекләндерү, Шоссе урамындагы ял зонасын төзекләндерү һәм Яшьләр урамындагы юлны төзекләндерү өчен тотуга Сез ризамы?» дигән сорау буенча 2021 елның 09 декабрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә, халык җыенында катнашучылар исемлегенә 145 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны- 92 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашкан 86 кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 6 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Буа муниципаль районы Югары Лашчы авыл җирлеге составына керүче Чуаш Аксуы авылында халык җыенын узган дип, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә, дип танырга.

2. «2021 елның 09 декабрендәге 1 номерлы Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Югары Лашчы авыл җирлегенең Чуаш Аксуы авылы гражданнары җыены карары нигезендә җыелган гражданнарның үзара салым акчаларын Чуаш Аксуы авылында юлларны төзекләндерү, Шоссе урамындагы ял зонасын төзекләндерү һәм Яшьләр урамындагы юлны төзекләндерү өчен тотуга Сез ризамы?» дигән сорау буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Буа муниципаль районының рәсми сайтында һәм Чуаш Аксуы авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халык җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Югары Лашчы авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: __________ Г.Х. Усманова

Югары Лашчы авыл җирлеге башлыгы ____________ Г.Х. Усманова